**ГЛАВА**
**Салаушского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

ул. Ленина, д.73 а, с. Салауши, Агрызский район, 422214

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Салагыш авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

Ленин ур., 73 а, Салагыш авылы, Әгерҗе районы, 422214

**Тел.: (85551) 3-74-38, Факс: 3-74-34. E-mail: Salaush.Agr@tatar.ru; www.agryz.tatarstan.ru**

11.10.2022 Салагыш авылы № 9

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уразай авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уразай торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 нче елның 27 октябрендә 17 сәг 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уразай торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Уразай урамнарын кардан чистарту (дизель ягулыгы һәм май сатып алу).

2. Уразай авылында урамнарны яктырту өчен лампалар, дроссельләр, фонарьлар, материаллар сатып алу һәм алыштыру;

3. Уразай авылы территориясендә су насослары, суүткәргеч челтәрләрне ремонтлау өчен сантехник материаллар сатып алу, су скважинасы казу;

4.Уразай авылындагы зиратны койма белән әйләндереп алу өчен материаллар сатып алу.

5.Уразай зираты юлына щебенка сатып алу һәм җәю.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Уразай авылы, Ленин урамы, 32А йорт, авыл клубында уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы М.М.МӨХӘММӘДИЕВ

Совет Салаушского сельского поселения
Салагыш авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002491